| | | |
|---|---|---|
| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 февраль, 2026 ел № 5/11

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы комиссиясе составын раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/18 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы комиссиясе турында Нигезләмә нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы Комиссиясе составын кушымтада каралган тәртиптә расларга.

1. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2018 елның 21 гыйнварындагы 23/12 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы комиссиясе турында Нигезләмәнең 3 пунктын;

2) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы комиссиясе составын раслау турында» 2018 елның 21 гыйнварындагы 23/12 номерлы Карарының 1 өлешен.

3. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының 5/11
Карарына кушымта
4 февраль, 2026 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи тәртип таләпләрен үтәү, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Шәһәр Советы Комиссиясе составы

1. Сәгыйдуллина Ирина Алексеевна – Комиссия рәисе, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары;
2. Әюпов Шамил Наил улы – Комиссия рәисе урынбасары, Шәһәр Советы депутаты - регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе;
3. Әдһәмова Лилия Шәүкәт кызы – Комиссия секретаре, Хаким (Шәһәр Советы) аппаратының оештыру-аналитик һәм хокукый эшләр идарәсе башлыгы;

Комиссия әгъзалары:

4. Евграфов Александр Петрович – Комиссия әгъзасы, Шәһәр Советы депутаты;
5. Миңнегалиев Раил Габделхәй улы – комиссия әгъзасы, Шәһәр Советы депутаты;
6. Мостафина Фәйрүзә Зөфәр кызы – Комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча);
7. Фәйсханов Рамил Рәшид улы – Комиссия әгъзасы, коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Хаким ярдәмчесе.